***Хөснетдинов Дамир Бәдретдин улы***

*Мин, Хөснетдинов Дамир Бәдретдин улы, 1944 нче елның 1 нче гыйнварында тудым. Әтием сугышта булмады, авырып калды. 1931 нче елгы абый, яше җитмәү сәбәпле, сугышка бармады. Мин 6 сыйныф белем алдым. Усадта УМХС №2 трактор йөртүчелеккә укыдым. Аннары шоферга укыдым. Сугыш вакытында бик кечкенә идем, бер нәрсә дә хәтерләмим. Сугыштан соң, 12 яшьтә кохозда ат җигеп эшләдем. Сугыш вакытында ашарга юк, күкәрин җыйганнар, аякларында чабата. 45 ел хезмәт стажым бар. Армиядә “младший сержант” дигән званиедә хезмәт иттем.*

*Хәзерге вакытта тормыш иптәшем белән тату гомер итәбез. 1 кыз, 1 малай үстердек. 3 оныгыбыз бар.*

*Хәзерге яшьләргә тәртипле булырга, тырышып укырга дигән теләктә калам. Хәзер мөмкинлекләр бар, укысыннар. Бәхетле булсыннар.*

